**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

2018 елның 7 марты №108

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Шәмбалыкчы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә**
**үзгәртүләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешу гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының" 14 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 мартындагы 61 номерлы “Шәмбалыкчы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәсен раслау турында” карары нигезендә кабул ителгән Шәмбалыкчы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1.1 пунктына түбәндәге үзгәрешләр өстәргә:

“Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә төзекләндерүнең, шулай ук Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары төзекләндерүгә һәм җирлек тирәсен төзекләндерү элементларына таләпләр билгеләүче, җирлек тирәсен төзекләндерү буенча чаралар исемлеген, аларны үткәрү тәртибен һәм вакытын билгеләүче Чын Кагыйдәләр”

б) 1.2 пунктына түбәндәге үзгәрешләр өстәргә:

“Төзекләндерүнең Чын Кагыйдәләре әлеге мәсьәләләрне хәл итә:

1) тирәлекне тотуны гомуми файдалану һәм шундый тирәлекне куллану тәртибе;

2) алгы якның тышкы күренеше һәм бина конструкцияләрен, корылмаларны киртәләү;

3) җир эшләрен башкарудан соң, төзекләндерү элементларын проектлаштыру, урнаштыру, карап тоту һәм торгызу;

4) җирлек территориясен, бина һәм корылмаларның архитектур яктыртылышын да кертеп, яктыртуны оештыру

5) җирлек территориясен яшелләндерүне, торак пунктлар чикләрендә урнашкан чирәмле үсемлекләр, газоннар, чәчәклекләр тоту, торгызу һәм саклау буенча тәртип булдыруны оештыру;

6) җирлек территориясендә, шул исәптән урам исемнәре һәм йорт номерлары язу, күрсәткечләр кую;

7) балалар һәм спорт мәйданчыклары, хайваннарны урамда йөртү өчен мәйданчыклар,  парковкалар (парковка урыннары), кече архитектура формалары урнаштыру һәм карап тоту;

8) җәяүлеләр өчен коммуникацияләр, шул исәптән тротуарлар, аллеялар, юл-сукмаклар булдыру;

9) инвалидлар һәм башка мөмкинлекләре чикле кешеләр төркеменең каршылыксыз хәрәкәт итүен тәэмин итү максатыннан, җирлек территориясен төзекләндерү;

10) җирлек территориясен җыештыру, кышкы чорны да исәпкә алып;

11) яңгыр суларын агызуны оештыру;

12) җир эшләрен үткәрүне тәртипкә салу;

13) муниципаль җирлек территориясендә бәйрәмнәрне рәсмиләштерү;

14)территорияне төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру һәм гражданнарның катнашуын оештыру;

15) җирлек территориясен төзекләндерүдә саклык кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуны гамәләгә ашырырга";

в) 6 пункттагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"территорияне төзекләндерү- җирлек территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен билгеләгән, гражданнарның яшәү шартларын һәм дәрәҗәсен күтәрү, уңайлылык тәэмин итүгә юнәлгән, әлеге территорияләрдә урнашкан объектларны, гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, территорияләрнең тирә-юне җирлекнең санитар һәм эстетик торышын яхшырту, торак пунктлары территорияләрен тоту буенча, төрле чаралар комплексын гамәлгә ашыручы эшчәнлек ул.

г) 6 пункттагы кырык дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"чикләнгән җирлек ул - әгәр җир кишәрлеге оешкан, Россия Федерациясе субъекты законы буенча территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләрен саклап чикләнгән булса, бина, корылма, җир кишәрлеге- гомуми файдаланудагы җирлек санала";

д) 6 пункттагы алтмыш дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"төзекләндерү элементлары булып,  декоратив, техник, планлаштырылган, конструктив төзелешләр, яшелләндерү элементлары, төрле төр җиһазлар һәм бизәлеш, шул исәптән фасадлар, биналар, корылмалар, кече архитектура формалары, капиталь булмаган корылмалар, территорияләрне төзекләндерү составына кергән мәгълүмати элмә һәм күрсәткечләр тора"

е) 98.10 пунктына түбәндәге эчтәлек өстәргә:

"98.10. Траспорт чараларының һәр тукталышында, шул исәптән социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектлары янында (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналары, физкультура-спорт, мәдәният һәм башка

оешмалар да кергән корылмалар, ял итү урыннары I, II төркем инвалидлар һәм , Россия Федерациясе билгеләгән тәртиптә III төркем инвалидлар йөрткән, инвалидларны яисә инвалид балаларны утырткан транспорт чараларының түләүсез парковка урыннары кимендә 10 процент (әмма кимендә бер урын) аерылып торырга тиеш. Транспорт чараларында "Инвалид" билгесе күрсәтелгән булырга тиеш. Шәхси куллану өчен "Инвалид" билгесен алу тәртибе Россия Федерациясе федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. Башка транспорт чараларына күрсәтелгән урыннарда парковка булырга тиеш түгел.”

2. 6 пунктның “г” подпункты 2018 елның 28 июнендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Уставы нигезендә билгеләнгән, махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Ф.Миннуллин**